**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«15» декабрь 2025 ел** **№ 18**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында**

«Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 13, 19, 26 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат районының Покровский поселогын бетерергә.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә «Татарстан Республикасы Нурлат районы Покровский поселогын бетерү һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кертергә.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән закон проектын караганда Нурлат муниципаль районы Советы вәкиле итеп Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башлыгы Дамир Азат улын Ишкинеевны билгеләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында https://nurlat.tatarstan.ru/ һәм «Дуслык» («Дружба», «Туслах») район газетасында бастырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев